СОВЕТ БУРЕВЕСТНИКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423194. с.Слобода Волчья, ул. Центральная, 29

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БУРЕВЕСТНИК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423194. Волчья Бистәсе. Үзәк урамы. 29

тел.: (8-84348) 36-1-31. факс: (8-84348) 36-0-97 эл. почта Burev.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
Буревестник авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

от «26» ноября 2024 года №50-152

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Буревестник авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Буревестник авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 19, 86-88 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Буревестник авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Буревестник авыл җирлеге Советының 10.03.2015 №38-89 карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Буревестник авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына (карарлар редакциясендә: №3-7 15.10.2015; №13-24 16.02.2016; №24-42 28.11.2016; №32-52 13.04.2017; №43-73 15.12.2017; №50-85 17.05.2018; №57-104 14.12.2018; №62-115 12.07.2019; №73-139 15.06.2020; №13-32 31.05.2021; №20-59 28.12.2021; №26-81 12.07.2022; №33-106 16.03.2023; №44-138 8.04.2024;) (алга таба – Устав) киләсе үзгәрешләр кертергә:

1.1. Уставның 5 статьясындагы 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 21 пункт өстәргә:
«21) «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру.»;

1.2. Уставның 41 статьясындагы 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 14 пункт өстәргә:
«14) аның чит ил агенты статусын алуы»;

1.3. Уставның 50 статьясына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 өлешнең 3 пунктындагы икенче абзацын үз көчен югалткан дип таныргa;

1 өлешнең 7 пунктындагы өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«- төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыра, аның предметы булып җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру тора;»;

1 өлешнең 10 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
«- шәхси ярдәмче хуҗалык турында 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә ала.»;

1.4. Уставның 73 статьяларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 һәм 2 өлешләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җирлек милкендә булырга мөмкин:

1) 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнгән мөлкәт;

2) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән очракларда җирлекнең җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мөлкәт, шулай ук җирлекнең җирле үзидарә органнарының аларга 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлешендә каралган тәртиптә тапшырылган аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мөлкәт;

3) «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының норматив хокукый актлары нигезендә җирлек җирле үзидарә органнары һәм җирлек җирле үзидарәсе вазыйфаи затлары, җирлек муниципаль хезмәткәрләре, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр хезмәткәрләре эшчәнлеген тәэмин итү өчен билгеләнгән мөлкәт;

4) хәл итү хокукы җирлекнең җирле үзидарә органнарына федераль законнар белән бирелгән һәм җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә кертелмәгән мәсьәләләрне хәл итү өчен кирәкле мөлкәт;

5) 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 3 һәм 4 өлешләре, 16 статьясындагы 3 өлеше һәм 16.2 статьясындагы 2 һәм 3 өлешләре нигезендә җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү өчен билгеләнгән мөлкәт, шулай ук 2003 елның 17 статьясындагы 1 һәм 1.1 өлешләре нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мөлкәт 06.10.2003 №131-ФЗ.

2.Җирлекнең әлеге статьяның 1 өлеше таләпләренә туры килми торган мөлкәткә милек хокукы барлыкка килгән очракларда күрсәтелгән мөлкәт яңадан профильләштерелергә (мөлкәтнең максатчан билгеләнеше үзгәрергә) йә читләштерелергә тиеш. Мондый мөлкәтне читләштерү тәртибе һәм сроклары федераль закон белән билгеләнә.»;

73 статьяның 3 өлешен үз көчен югалткан дип танырга.

1.5. Уставның 74 статьясына түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә;

«4. Җирле үзидарә органнары Россия Федерациясенең электр энергетикасы турындагы законнарында билгеләнгән очракларда, тәртиптә һәм шартларда Муниципаль милектәге, система барлыкка китерүче территориаль челтәр оешмасына яисә Россия Федерациясе субъекты чикләрендә эш итүче территориаль челтәр оешмасына электр челтәре хуҗалыгы объектларын түләүсез биләүгә һәм файдалануга тапшыруны гамәлгә ашыралар.».

2. Бу карарны дәүләт теркәлүе өчен законда билгеләнгән тәртиптә җибәрергә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» нда: https://pravo.tatarstan.ru «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Буревестник авыл җирлеге Советының Законлылык, экология, Җирдән файдалану, торак-коммуналь хуҗалыгы һәм территориясен төзекләндерү мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә
муниципаль районы Буревестник
авыл җирлеге башлыгы

Ю.М. Улитин